| Республика Татарстан<br>Совет Старомензелябашского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Иске Минзәләбаш авыл җирлеге<br>Советы |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 август 2019 ел №14

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» гы 16нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон , Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзщлщбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендэ, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ :

1. Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» гы 16нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1) 4 бүлекнең 4.1.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.Гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә алдагы этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO) TATARSTAN.RU («Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы рәисе А.Р.Мияссарова

Совет Старомензелябашского сельского поселения ОГРН 1021601312237 ИНН 1636001393